| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«САРАБИКУЛОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«САРАБИККОЛ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 6 июне № 16

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 11а номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 14нче статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының "Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатыннан чыгып, Сарабиккол авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 11а номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

19 пунктның 2 пунктчасын, 17, 70, 99, 111 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»

2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гомуми кулланылыштагы яшелләндерү территорияләре чикләрендә - муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алуны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча башкаручы»;

«17. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм җыештыру «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алуларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча билгеләнгән башкаручы тарафыннан гамәлгә ашырыла»;

«70. Юлларны карап тоту «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алуларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча билгеләнгән башкаручы тарафыннан гамәлгә ашырыла»;

«99. «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алуларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча билгеләнгән башкаручы тарафыннан башкарыла»;

«111. Кече архитектура рәвешләрен карап тоту бирелгән җир участоклары чикләрендә, гомуми файдалану территорияләрендә җир кишәрлекләре хокукына ия булган кешеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла, гомуми кулланылыштагы территорияләрдә - «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алулар нәтиҗәләре буенча билгеләнгән башкаручы тарафыннан гамәлгә ашырыла».

2. Әлеге карарны Сарабиккол авыл җирлегендә урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://Ieninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль

берәмлеге башлыгы, Совет рәисе Г.Р.Гаделшина